# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
# ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

*(үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән)*

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең (алга таба – Авыл җирлеге) үтәү-боеру вазыйфаларын гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы булып тора.

1.2. Башкарма комитет үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Конституцияләренә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларына, Авыл җирлеге уставына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Башкарма комитет үзенең эшчәнлеген Авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимиятнең территориаль органнары, муниципаль районның җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек итеп гамәлгә ашыра.

## 2. Юридик статусы

2.1. Башкарма комитет муниципаль казна учреждениеесе формасындагы юридик зат булып тора.

2.2. Башкарма комитетның мөһере, штамплары, үз исеме белән бланклары, банк учреждениеләрендә Россия Федерациясе законнары нигезендә исәп-хисап һәм бүтән төрле счетлары була. Башкарма комитет мөлкәти һәм мөлкәти булмаган хокукларны һәм йөкләмәләрне сатып алырга һәм гамәлгә ашырырга, судта дәгъва белдерүче яки җаваплы як буларак чыгыш ясарга хокуклы, аның мөстәкыйль балансы була.

2.3. Башкарма комитет урнашкан урын: Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 йорт.

## 3. Башкарма комитетның төп бурычлары һәм вазыйфалары

3.1. Башкарма комитет Татарстан Республикасы Авыл җирлеге территориясендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вазыйфаларын үтәүне, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен, шулай ук муниципаль район составына керә торган авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны оештыра.

3.2. Башкарма комитет компетенциясенә җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләр керә:

– билгеләнгән тәртиптә Авыл җирлеге халкы яки Советы тарафыннан

кабул ителгән карарларның, Авыл җирлеге башлыгы карарларының һәм боерыкларының үтәлешен оештыру;

– Авыл җирлеге бюджеты проектын формалаштыру, раслау өчен Авыл җирлеге Советына тапшыру;

– федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Авыл җирлеге Уставына туры китереп, Авыл җирлеге бюджетын үтәү;

– Авыл җирлеге Советы тарафыннан расланган тиешле Нигезләмә нигезендә Авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтендә торган мөлкәттән файдалану һәм аның белән эш итү;

– Авыл җирлегендәге торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү;

– Авыл җирлегендә яшәүчеләрне элемтә хезмәтләре, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

– Авыл җирлегендә яшәүчеләрнең ялын оештыру һәм аларны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

– Авыл җирлеге территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү, Авыл җирлегенең рәсми физик культура-савыктыру һәм спорт чараларын уздыруны оештыру өчен шартлар тәэмин итү;

– Авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыру;

– Авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарның аталышлары һәм йортларны номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыруны һәм карап тотуны да кертеп);

– адресацияләү объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, гамәлдән чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яки муниципальара әһәмияттәге, муниципаль районның муниципаль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан гайре) исемнәр, Авыл җирлеге чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыру;

– авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә ярдәм итү, кече һәм урта эшкуарлык өчен шартлар тудыру;

– Авыл җирлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

– җәмәгатьчелек тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә булышлык күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

– Авыл җирлеге музейларын булдыру;

– Авыл җирлегендә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләрне башкару;

– опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруда катнашу;

– Авыл җирлеге территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

– Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм Авыл җирлеге территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтү;

– Авыл җирлеге территориясендә булган муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең мобилизацияле әзерлеге буенча чараларны оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

– муниципаль янгын сагы булдыру;

– туристлыкны үстерү өчен шартлар тудыру;

– кеше хокукларын тәэмин итүне иҗтимагый тикшереп торуны һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм итү;

– инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның россиякүләм иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан булдырылган оешмаларга ярдәм итү;

– федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтелүнең сыйфатына бәйсез бәяләү уздыруны оештыру өчен шартлар тудыру;

– торак законнарына туры китереп социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләре буенча гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү;

– каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аралап җыю) һәм транспорт белән күчерү эшчәнлеген оештыруда катнашу;

– йола буенча үткәрелә торган хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту;

– Авыл җирлеге чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су агызуны, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

– Авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

– милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) каршылыкларны кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

– Авыл җирлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ялы өчен шартлар тудыру һәм, гражданнарның уртак файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иркле үтеп керә алуын тәэмин итүне дә кертеп, халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

## 4. Башкарма комитетның вәкаләтләре

Башкарма комитет куелган бурычларны үтәү һәм үзенең вазыйфаларын гамәлгә ашыру өчен түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

4.1. Планлаштыру, бюджет, финанслар һәм исәпкә алу өлкәсендә:

– Авыл җирлеге бюджеты проектын, Авыл җирлеген комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары проектларын эшли;

– Авыл җирлеге бюджеты үтәлешен тәэмин итә, Авыл җирлеген комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары үтәлүен

оештыра;

– Авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында хисап, Авыл җирлеген комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары үтәлүе турында хисаплар әзерли;

– Авыл җирлегенең икътисадый торышын һәм социаль өлкәсен сыйфатлый торган статистика күрсәткечләре җыелуын һәм аталган белешмәләрнең законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшырылуын оештыра.

4.2. Муниципаль мөлкәт белән идарә итү, Авыл җирлеге территориясендә предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

– Авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтендә торучы мөлкәт белән идарә итә, муниципаль мөлкәт объектларын булдыруга, сатып алуга, файдалануга, алар белән эш итүгә һәм аларның арендасына бәйле мәсьәләләрне хәл итә;

– Авыл җирлеге Советы карарында билгеләнгән очракларда, муниципаль мөлкәтне читләштерү турында, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында, тәкъдимнәр әзерли һәм килештерү (раслау) өчен Авыл җирлеге Советына кертә;

– муниципаль мөлкәттә тормаучы предприятиеләр, оешмалар белән Авыл җирлеген икътисадый һәм социаль үстерүдә хезмәттәшлек итү турында шартнамәләр төзи; Авыл җирлеге территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милекчелек формаларындагы предприятиеләрне булдыруга ярдәм итә;

– Авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль казна учреждениеләре булдыра, аларның максатларын, эшчәнлек итү шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, муниципаль учреждениеләрне финанслауны тәэмин итә, муниципаль учреждениеләрне һәм предприятиеләрне үзгәртеп кору һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итә, контракт нигезендә аларга җитәкчеләр билгели һәм биләгән вазыйфаларыннан азат итә;

– муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыра; Авыл җирлеген төзекләндерү, халыкка коммуналь хезмәт күрсәтү, социаль инфраструктура объектларын төзү һәм төзәтү, халыкның көнкүреш һәм социаль-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле продукцияне җитештерү, хезмәтләр күрсәтү эшләрен, моның өчен каралган Авыл җирлегенең шәхси матди һәм финанс чараларыннан файдаланып, башка эшләрне башкаруга заказчы сыйфатында катнаша;

– авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә булышлык күрсәтә, кече һәм урта эшкуарлык өчен шартлар тудыра;

– Авыл җирлеге музейларын булдыра.

4.3. Территориаль планлаштыру, җирдән һәм башка табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә табигать тирәлеген саклау өлкәсендә:

– муниципаль мөлкәттә торучы җирләрне планлаштыруны һәм алардан рациональ файдалануны һәм аларны саклауны оештыруны гамәлгә ашыра;

– Авыл җирлеге чикләрендә җирләрне резервка куюны һәм, шул исәптән сатып алу юлы белән, җир кишәрлекләрен муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алуны гамәлгә ашыра;

– халыкка экологик вәзгыять турында мәгълүмат ирештерә,

әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудыручы, табигатьтән файдалану турында законнарны бозучы предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның гамәлләре турында тиешле органнарга хәбәр итә;

4.4. Гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итү өлкәсендә:

– билгеләнгән тәртиптә социаль найм шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар сыйфатында гражданнарның исәбен алып бара;

– торак законнарына туры китереп, социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләре буенча гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү турында карар кабул итә.

4.5. Торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм халыкка башка төрле хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

– халыкны элемтә хезмәтләре, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудырылуын тәэмин итә;

– халыкның ялын оештыру һәм аларны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

– туристлыкны үстерү өчен шартлар тудыра;

– Авыл җирлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыра һәм гамәлгә ашыра;

– Авыл җирлегендә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләрне башкара;

– Авыл җирлеге территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү, Авыл җирлегенең рәсми физик культура-савыктыру һәм спорт чараларын уздыруны оештыру өчен шартлар тәэмин итә;

– милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, Авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) каршылыкларны кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра.

4.6. Төзекләндерү өлкәсендә:

– Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне һәм яшелләндерүне оештыра;

– урамнарны яктыртуны һәм урамнарның исемнәре һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр урнаштырылуны тәэмин итә;

– кече архитектура формаларын урнаштыра һәм карап тота;

– каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аралап җыю) һәм транспорт белән күчерү эшчәнлеген оештыруда катнаша;

– йола буенча үткәрелә торган хезмәтләр күрсәтүне һәм җирләү урыннарын карап тотуны оештыра;

– Авыл җирлеге чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су агызуны, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыра;

– Авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

– Авыл җирлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ялы өчен шартлар тудыру һәм, гражданнарның уртак файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иркле үтеп керә алуын тәэмин итүне дә кертеп, халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыра.

4.7. Гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә:

– Авыл җирлеге өлкәсендә законнарның, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары актлары үтәлүен, гражданнарның хокуклары һәм ирекләре саклануын тәэмин итә;

– билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яки арбитраж судында дәүләт хакимияте органнарының һәм дәүләт вазыйфаи затларының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның җирле үзидарә хокукын боза торган актларына шикаять белдерә;

– Авыл җирлегендәге торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чаралар уздырылуын тәэмин итә;

– Авыл җирлеге территориясендә булган муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең мобилизацияле әзерлеге буенча чараларны оештыра һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

– опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруда катнаша;

– муниципаль янгын сагы эшен оештыра;

– муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, Авыл җирлеге Советы депутатын алу буенча тавыш бирүне, Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, Авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм бу чараларны уздыруны оештыруны һәм матди-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

– җәмәгатьчелек тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә булышлык күрсәтә, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыра;

– кеше хокукларын тәэмин итүне иҗтимагый тикшереп торуны һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм итә;

– инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның россиякүләм иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан булдырылган оешмаларга ярдәм итә.

4.8. Федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:

– федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

– дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди һәм финанс чараларының исәбен алып бара һәм аларның тиешенчә файдалануын тәэмин итә;

– тиешле федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшыра;

– Авыл җирлеге Советы карарлары нигезендә, үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен, Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары карамагында торган матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалануны тәэмин итә.

4.9. Бүтән вәкаләтләр:

– Авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник яктан һәм башкача тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

– Авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыруны гамәлгә ашыра;

– үз вәкаләтләре кысаларында, федераль законнарга туры китереп, халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыра;

– муниципаль хезмәтләр реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен билгели;

– «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы законнарында авыл җирлекләренә беркетелгән җирле әһәмияттәге, шулай ук Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешүләр нигезендә Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшырылган мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

– законнарда, әлеге Уставта, Авыл җирлеге Советы карарларында Авыл җирлеге компетенциясенә яки Авыл җирлеге җирле үзидарәсенең бүтән органнары вәкаләтенә кертелгән вәкаләтләрдән тыш, Авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

– Авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү максатларында Авыл җирлеге өчен социаль әһәмиятле булган эшләрне (шул исәптән кизү торуларны) ирекле нигездә башкару өчен гражданнарны җәлеп итү турында карарлар кабул итә һәм аларның уздырылуын оештыра.

Социаль әһәмиятле эшләргә фәкать махсус һөнәри әзерлек таләп итми торган эшләр генә кертелә ала.

Социаль әһәмиятле эшләрне башкаруга төп эшеннән яки укудан буш вакытында Авыл җирлегендә яшәүче хезмәткә сәләтле балигълык яшенә җиткән кешеләр өч айга бер мәртәбәдән артмаган ешлыкта түләүсез нигездә җәлеп ителергә мөмкин. Бу вакытта социаль әһәмиятле эшләрнең озынлыгы рәттән дүрт сәгатьтән артыграк була алмый.

## 5. Авыл җирлеге башлыгы

5.1. Авыл җирлеге башкарма комитетына Авыл җирлеге Советы тарафыннан сайлап куела торган авыл җирлеге Башлыгы җитәкчелек итә.

5.2. Үзенең эшчәнлегендә авыл җирлеге Башлыгы Совет тикшерүендә тора һәм аның алдында хисап тота һәм Башкарма комитетка йөкләнгән бурычларның үтәлүе һәм аның үз функцияләрен гамәлгә ашыруы өчен шәхсән җаваплы була.

5.3. Авыл җирлеге Башлыгы вакытлыча булмый торган очракта башкарма комитет функцияләре вазыйфаларын башкарма комитет сәркатибе үти.

5.4. Авыл җирлеге Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, аның вазыйфаларын конкурс нәтиҗәләре буенча авыл җирлеге Башлыгы вазыйфасына башка кандидатура сайланганчыга кадәр авыл җирлеге Советында аның урынбасарларының берсе башкара.

5.5. Авыл җирлеге Башлыгы үз вәкаләтләре чикләрендә карарлар һәм боерыклар чыгара. Авыл җирлеге Башлыгы хокукый актларын әзерләү, аларны килештерү һәм имзалау тәртибе авыл җирлеге Башлыгы раслый торган

Нигезләмәдә билгеләнә. Авыл җирлеге Башлыгының хокукый актлары, әгәр актның үзендә башкача каралмаса, аларга имза куелган көннән үз көченә керә. Авыл җирлеге Башлыгының хокукый актлары Авыл җирлеге территориясендә урнашкан барлык предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, иҗтимагый һәм дини берләшмәләр, шулай ук гражданнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан авыл территориясендә үтәү өчен мәҗбүри булып тора.

Кешенең һәм гражданинның хокукларына, ирекләренә һәм вазыйфаларына кагыла торган муниципаль хокукый актлар аларны рәсми рәвештә бастырып чыгаргач (халыкка җиткергәч) үз көченә керә

5.6. Үтәү-боеру эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә авыл җирлеге Башлыгы:

– башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә Авыл җирлеге һәм Авыл җирлеге Советы исеменнән эш итә;

– Авыл җирлеге бюджеты проектын һәм аны үтәү турындагы хисапларны Авыл җирлеге Советына карау өчен тапшыра;

– Авыл җирлеген комплексլы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары проектларын һәм аларны үтәү турындагы хисапларны карау өчен Авыл җирлеге Советына тапшыра;

– Башкарма комитет структурасы проектын карау өчен Авыл җирлеге Советына кертә, расланган структура нигезендә, хезмәткәрләрнең билгеләнгән чик исәбе һәм хезмәткә түләү фонды белән, Авыл җирлеге Башкарма комитетының штат расписаниесен раслый;

– муниципаль хезмәткәрләрне һәм Авыл җирлеге Башкарма комитетындагы бүтән хезмәткәрләрне вазыйфаларына билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга карата бүләкләү һәм дисциплинар җаваплылык чараларын күрә;

– расланган бюджет нигезендә Авыл җирлеге акчасы белән эш итә, банк учреждениеләрендә бюджет һәм бүтән счетларны ача һәм яба;

– федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра һәм (яки) аларның Авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырылуын тәэмин итә, аларның үтәлеше өчен шәхси җаваплы була; законнар нигезендә һәм аларны үтәү максатында тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча хокукый актлар чыгара;

– Авыл җирлегенең Башкарма комитеты компетенциясенә кертелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча хокукый актлар, шулай ук Авыл җирлеге Башкарма комитетының эшен оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар чыгара;

– елга бер мәртәбәдән артмаган ешлыкта Авыл җирлеге Советына үзенең эшчәнлеге һәм Авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлеге турында хисаплар тапшыра;

– Авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлеге турында халыкка даими рәвештә мәгълүмат җиткерә, Авыл җирлеге Башкарма комитеты хезмәткәрләренең гражданнарны кабул итүен оештыра, бер айга бер мәртәбәдән артмаган ешлыкта гражданнарны кабул итә, гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый, алар буенча карарлар кабул итә;

– дәүләт һәм бүтән органнарда Авыл җирлеге мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар күрә, Авыл җирлеге Башкарма комитеты исеменнән судка гаризалар тапшыра, ышанычнамәләр бирә;

– Авыл җирлеге Башкарма комитетының аның компетенциясенә керә торган вәкаләтләрне үтәве өчен шәхси җаваплы була;

– законнар, Авыл җирлеге Уставы, Авыл җирлеге Советы карарлары һәм төзелгән контракт нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

5.7. Авыл җирлеге Советы белән үзара хезмәттәшлек итү өлкәсендә авыл җирлеге Башлыгы Авыл җирлеге Советына түбәндәгеләрне кертә:

– Башкарма комитет структурасы турында тәкъдимнәр;

– Авыл җирлеге Советының норматив хокукый актлары проектларын;

– җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүне, үзгәртүне һәм гамәлдән чыгаруны, җирле бюджет акчасына чыгымнар тотуны күздә тотучы тәкъдимнәрне;

– Авыл җирлеге Советының чираттан тыш утырышларын чакырту турында тәкъдимнәр;

– Авыл җирлеге Советы утырышлары өчен көн тәртибе турында тәкъдимнәр.

## 6. Башкарма комитет эшчәнлеген оештыру

6.1. Башкарма комитетның структурасы авыл җирлеге Башлыгы күрсәтүе буенча Авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана.

6.2. Авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасына авыл җирлеге Башлыгы, башкарма комитет сәркатибе, Башкарма комитетның бүтән вазыйфаи затлары һәм (яки) тармак (вазыйфаи) органнары керә.

6.3. Авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлегендә булышлык күрсәтү, аның компетенциясенә кертелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча бурычларны хәл итүне килештерү өчен Авыл җирлеге Башкарма комитеты каршында авыл җирлеге Башлыгы карары нигезендә координацияләү, эксперт һәм башка төрле иҗтимагый (консультация) советлары төзелергә мөмкин. Аталган советлар Авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасына керми. Аларда эшләү иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашырыла.

## 7. Хезмәт мөнәсәбәтләре

7.1. Башкарма комитетта хезмәт итү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәт булып тора. Башкарма комитетта муниципаль вазыйфаларда хезмәт итүче затлар муниципаль хезмәткәрләр булып тора.

7.2. Башкарма комитетның һәм хезмәткәрләрнең (муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль хезмәткәр булып тормаучы техник хезмәткәрләрнең) мөнәсәбәтләре хезмәт законнары, муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән җайга салына.

7.3. Башкарма комитетның һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең һәм предприятиеләрнең җитәкчеләренең мөнәсәбәтләре хезмәт

законнары, граждан законнары, әлеге Нигезләмә, үзләре белән төзелә торган хезмәт шартнамәләре нигезендә җайга салына.

7.4. Башкарма комитет хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү законнарда һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

7.5. Башкарма комитет хезмәтне саклау буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган чараларны гамәлгә ашыра һәм законнарда билгеләнгәнчә җаваплы була.

## 8. Башкарма комитетның мөлкәте һәм финанс эшчәнлеге

8.1. Башкарма комитет Авыл җирлеге бюджетында бу максатлар өчен каралган акча чикләрендә чыгымнар сметасына туры китереп, шулай ук законнарда тыелмаган башка чыганаклар хисабына да финанслана.

8.2. Башкарма комитетның финанс һәм икътисадый нигезен түбәндәгеләр тәшкил итә: Авыл җирлеге бюджетындагы акчалар, Башкарма комитет карамагына тапшырылган вазыйфаларны тәэмин итү өчен булдырылган муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр, шулай ук идарә вазыйфаларын гамәлгә ашыру өчен Башкарма комитетка тапшырылган бүтән муниципаль мөлкәт.

## 9. Башкарма комитетны бетерү һәм үзгәртү

9.1. Башкарма комитетны бетерү һәм үзгәртеп кору федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.